КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 6 декабрь г.Казань № 1564

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә М-12 «Мәскәү – Түбән Новгород – Казан» тиз йөрешле автомобиль юлын проектлау һәм төзүне алып бару буенча эшче төркем турында нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында» 2020 ел, 17 октябрь, 938 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә М-12 «Мәскәү – Түбән Новгород – Казан» тиз йөрешле автомобиль юлын проектлау һәм төзүне алып бару буенча эшче төркем турында нигезләмәне һәм аның составын раслау хакында» 2020 ел, 17 октябрь, 938 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 26 декабрь, 1196 нчы, 2021 ел, 16 август, 736 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә М-12 «Мәскәү – Түбән Новгород – Казан» тиз йөрешле автомобиль юлын проектлау һәм төзүне алып бару буенча эшче төркем турында нигезләмәдә:

II бүлекнең бишенче абзацында «дәүләт хакимияте республика башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

III бүлектә:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «Республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә М-12 «Мәскәү – Түбән Новгород – Казан» тиз йөрешле автомобиль юлын проектлау һәм төзүне алып бару буенча эшче төркем составында:

эшче төркем составыннан А.М.Шиһаповны чыгарырга;

эшче төркем составына Гобәйдуллин Илнур Ирек улын, Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге баш дәүләт инспекторын кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин